ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» марта 2025 ел № 83

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 04.08.2017 елның 344 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.03.2015 елның 160 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 04.08.2017 елның 344 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында» 04.08.2017 елның 344 номерлы карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында».

1.2. Расларга:

- физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыру чыгымнары нормалары;

- спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларында катнашучыларны яшәтү чыгымнары нормалары;

2. Тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карар нигезендә чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә әлеге карар нигезендә чыгымнарны вакытында каплау.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatartan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Н. Бадахшинга йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.03.2025 елның
83 номерлы карары белән расланды

Физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыру чыгымнары нормативлары

| № | Спорт чаралары аталышы | Көненә бер кешегә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралар | 365 кә кадәр |
| 2. | Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга тренировка чаралары (спартакиадалар, универсиадалар) | 425 кә кадәр |
| 3. | Бөтенроссия ярышлары һәм аларга тренировка үткәрү чаралары | 730 кә кадәр |
| 4. | Олимпия һәм паралимпия булмаган спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга тренировка чаралары | 785 кә кадәр |
| 5. | Олимпия һәм паралимпия спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга тренировка чаралары | 850 кә кадәр |

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.03.2025 елның
83 номерлы карары белән расланды

Спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларында катнашучыларны яшәтү чыгымнары нормативлары

| № | Яшәү өчен торак пунктлар категорияләре исеме | Бер кеше бәясе - бер көн, сум |
|---|---|---|
| 1. | Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләре | 1120 кә кадәр |
| 2. | Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре; Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 910 - 1120 |
| 3. | Россия Федерациясе территориясендә башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 670 - 850 |